# «БАТЫР ЯКТАШЫБЫЗ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП...”

**«БАТЫР ЯКТАШЫБЫЗ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП...”**

***Җиңү көне —***
***Халык тантанасы,***
***Яз төренгән янар комачка.***
***Җир чәчәкләр тезгән күкрәгенә,***
***Йөз балкытып карый кояшка.***

Илебезнең барлык халыклары белән бергә авыр көрәштә татар язучылары да катнаштылар; язучы, журналист буларак фронт газеталарында хезмәт иттеләр, кулларына корал алып алгы сызыкларда сугыштылар. Аларның күбесе сугыштан әйләнеп кайтмады, изге җиребез өчен гомерен бирде.

Туган тел атналыгында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына һәм  М.Җәлилнең туган көненә багышлап Кодаш мәдәният йорты мөдире Ёлшина Елена Викторовна нәфис сүз бәйгесе оештырды.Китапханәче Загидуллина Ирина Илгинар кызы кичәгә Муса Җәлил иҗаты һәм аның турындагы барлык әдәбиятны туплап китап күргәзмәсе әзерләде, җәлилчеләргә багышланганмультимедиа проекторы аша “Туган илнең батыр уллары” приезентациясен күрсәтте.

Яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүне камилләштерү максатыннан мәктәп укучылары һәм балалар бакчасы балалары арасында Бөек Ватан сугышында катнашкан татар язучыларының шигырьләрен сәнгатьле уку буенча кичә узды. Талантларны барлау, милли мәдәниятны үстерү, туган телгә сөю тәрбияләүне максат итеп куйган чарада 14 бала катнашты. Аларны яшь буенча 3 төркемгә бүлеп, нәтиҗә ясалды.

5-7 яшьлек балалар арасында беренче урынны Сафиуллина Самира,  икенче урынны Җиһаншина Чулпан, өченче урынны Хөснетдинова Руслана яуладылар. Иң яшь шигырь сөйләүче номинациясендә Сәфәров Эмиль (4 яшь), Гәрәйһәнова Алинә һәм Кучарбайева Эльвина актив катнаштылар.

8-12 яшьлекләр арасында беренче урын – Патрикеев Данила, икенче урында, Калимуллина Айзилә һәм өченче урынны Сәфәров Камил яуладылар

12-15 яшьлекләр арасында беренче урынны Калимуллин Илдан, икенче урынны ике кыз Галиева Эльвина һәм Зайдуллина Эльза бүлделәр, өченче урынны Мияссаров Илназ алды. Имамова Дианага актив катнашкан өчен рәхмәт.

Җюри әгъзалары исеменнән Арысланова Равилә Лотфулла кызы гомуми нәтиҗәне игълан итәргә чыкты: “Яшь буынга патриотик тәрбия бирү – безнең зур бурычларның берсе. Үткәрелгән бәйрәм шуны дәлилләүче  чара булып тора. Былтыргы нәфис сүз бәйгесенә караганда, быел балалар яхшырак әзерләнгәннәр, кайбер бала йөрәккә үтәрлек итеп шигырьләрен сөйләде”, дип рәхмәтен белдерде. Балаларны, дипломнар һәм дә тәмле презентлар белән бүләкләделәр.

***Сугыш беркайчан да булмаска тиеш.***

***Я, әйтегез, сугыш кемгә кирәк икән?***
***Һәр адәмнең газиз башы бит бер генә,***
***Бу дөньяда безне сөеп кеше иткән***
***Якты, изге җәннәтебез – тик Җир генә!***